Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
14.11.2025 ел

КАРАР
№4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Җәлил шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә 2026 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирә:

1. 2025 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

Үткәрү урыны: Мәдәният сарае, адресы: ТР, Сарман муниципаль районы, пгт.Җәлил, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 6 нчы йорт.

2. 2025 елның 28 ноябрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

Үткәрү урыны: Мәдәният сарае, адресы: ТР, Сарман муниципаль районы, пгт.Җәлил, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 6 нчы йорт.

3. 2025 елның 29 ноябрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

Үткәрү урыны: Мәдәният сарае, адресы: ТР, Сарман муниципаль районы, пгт.Җәлил, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, 6 нчы йорт.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту (материаллар сатып алу, шартнамә буенча түләү);

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогында Җәлил урамы, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, Әхмәдиев урамы, Урман урамы буенча тротуарлар төзү, ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогындагы «каз " күлен төзекләндерү (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогында янгын гидрантын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү));

«РИЗА» ««КАРШЫ?»

6. Әлеге карарны «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән жиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы»
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы — Р. Ә. Каримов